РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН

**СОВЕТ ЧИСТОПОЛЬСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА**

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ

**ЧИСТАЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ СОВЕТЫ**

***Решение*** ***Карар***

**2025 елның 29 декабре** **Чистай шәһәре** **№ 6/5**

**Чистай муниципаль районы Советының “Сатулар үткәрмичә гамәлгә ашырыла торган җир кишәрлекләренең бәясен билгеләү тәртибе турында, җир кишәрлекләре өчен аренда түләве күләмнәрен билгеләү тәртибе турында, хосусый милектәге җир кишәрлекләренең мәйданын арттыру өчен аларның муниципаль милектәге җир кишәрлекләре белән яңадан бүлешүе нәтиҗәсендә түләү күләмен билгеләү тәртибе турында һәм җир кишәрлекләренә карата сервитут билгеләү турында килешү буенча түләү күләмен билгеләү тәртибе хакында” 2024 елның 27 декабрендәге 37/3 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында**

Җир кишәрлекләреннән нәтиҗәле файдалану максатларында, Россия Федерациясенең, Татарстан Республикасының гамәлдәге законнары нигезендә, Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районы Советы

**КАРАР ИТТЕ:**

1. Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районы Советының “Сатулар үткәрмичә гамәлгә ашырыла торган җир кишәрлекләренең бәясен билгеләү тәртибе турында, җир кишәрлекләре өчен аренда түләве күләмнәрен билгеләү тәртибе турында, хосусый милектәге җир кишәрлекләренең мәйданын арттыру өчен аларның муниципаль милектәге җир кишәрлекләре белән яңадан бүлешүе нәтиҗәсендә түләү күләмен билгеләү тәртибе турында һәм җир кишәрлекләренә карата сервитут билгеләү турында килешү буенча түләү күләмен билгеләү тәртибе хакында” 2024 елның 27 декабрендәге 37/3 номерлы карарына, 1 нче кушымтаның 3 пунктындагы 2 пунктчасын яңа редакциядә бәян итеп, үзгәрешләр кертергә:

"2) бакчачылык яисә яшелчәчелек коммерциягә карамаган ширкәтенә, мондый ширкәт әгъзасына бирелгән җир кишәрлегеннән барлыкка килгән бакча җир кишәрлеге яисә яшелчә җир кишәрлеге".

2. Әлеге карарны массакүләм мәгълүмат чараларында - "Чистай хәбәрләре" газетасында, Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында

(pravo.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга һәм Чистай муниципаль районының рәсми сайтында - www.chistopol.tatarstan.ru урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Чистай муниципаль районы Советының законлылык, хокук тәртибе һәм депутат эшчәнлеге мәсьәләләре буенча даими депутат комиссиясенә йөкләргә.

Чистай муниципаль районы
башлыгы

Д.А. Иванов